**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

егерме беренче утырыш
**КАРАРЫ**

08 сентябрь 2022 ел **№ 142** Теләче ав.

Теләче муниципаль район Советының 2018 елның 12 апрелендәге 124 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыкларының урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык акчалата түләүләре күләмнәрен арттыру турында» карары нигезендә, Теләче муниципаль район Советы **карар итте:**

1. Теләче муниципаль район Советының 2018 елның 12 апрелендәге 124 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмә» карарына (24.08.2018 № 136, 20.11.2019 № 209, 09.10.2020 № 9, 12.11.2021 № 86, 29.04.2022 № 125 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 11 958 сум күләмендә расларга.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы Н.Н. Хаҗипов